| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| --- | --- |

РЕШЕНИЕ КАРАР

01.02.2022 г.Лениногорск № 11

Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 54 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр жир өсте транспортында һәм юл хужалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Лениногорск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 54 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр жир өсте транспортында һәм юл хужалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Лениногорск муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Лениногорск муниципаль районы Советының «Лениногорск муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр жир өсте транспортында һәм юл хужалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 54 номерлы карарының «Лениногорск муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр жир өсте транспортында һәм юл хужалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәжбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» 2 номерлы нигезләмәсен тәкъдим ителгән редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск
муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
Лениногорск район Советы карарына
кушымта
01.02.2022 ел № 11

**Лениногорск муниципаль районында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын, шул исәптән автомобиль юлларын, автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларны, юл буе полосаларын төзекләндерү элементларын пычрату һәм (яки) зыян китерү турында мәгълүмат килү.

2. Юл эшчәнлеген башкарганда мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булу.

3. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларында һәм (яки) юл буе полосаларында урнашкан юл сервисы объектларын эксплуатацияләгәндә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре булу.

4. Автомобиль юлларын һәм (яки) юл корылмаларын проектлаганда, төзегәндә, реконструкцияләгәндә, ремонтлаганда һәм карап тотканда, капиталь төзелеш объектларының, юл эшчәнлеген башкару өчен билгеләнгән объектларның, юл сервисы объектларының юл буе полосалары чикләрендә, шулай ук автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын урнаштырганда, мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләрнең һәм шартларның гамәлдә булу вакыты чыгу турында мәгълүмат килү.

5. Автомобиль юлының һәм (яки) юл корылмаларының аларны төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонт үткәрү, ремонтлау һәм карап тоту буенча мәҗбүри таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат килү.

6. Юл эшләре башкарганда мәҗбүри таләпләрне бозу турында мәгълүмат килү.